ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге каршында
Хатын-кызлар советын оештыру турында

Хатын-кызлар һәм балалар мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру, Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең иҗтимагый-сәяси, икътисадый, социаль һәм мәдәни тормышында хатын-кызларның ролен күтәрү максатында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 10 нчы Федераль закон нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1 Актаныш муниципаль районының Хатын-кызлар советын төзергә.

2. Актаныш муниципаль районының Актаныш авыл җирлеге каршындагы Хатын-кызлар советы турындагы Нигезләмәне расларга.

3. Актаныш авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие һәм учреждениеләр җитәкчеләренә Хатын-кызлар советы эшчәнлеген оештыруда ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Актаныш авыл җирлеге
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы И.Ш.Бариев

Актаныш муниципаль районы
Актаныш авыл җирлеге Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы карары
белән______________ №___
расланган

## Актаныш муниципаль районының Актаныш авыл җирлеге Хатын-кызлар советы турында нигезләмә

### 1.Гомуми нигезләмә

Хатын-кызлар советы - Актаныш муниципаль районы җирлегендә яшәүче гражданнарның мәнфәгатьләрен яклау өчен төзелгән ирекле, бәйсез иҗтимагый оешма.

Оешма социаль гаделлек өчен чыгыш ясый, иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итә, гаиләләргә ярдәм күрсәтә, хатын-кызларның проблемаларын хәл итә, эшлекле һәм кирәкле мәсьәләләрне күтәрә.

### 2. Максаты.

Җәмәгать эшләрендә хатын-кызларның актив катнашуы өчен иң уңай шартлар тудыру.

3. Эшчәнлек.

Хатын-кызларның мәнфәгатьләрен яклау, гаиләләрне саклау, ятимлеккә хөкем ителгән, ата-ана кайгыртуыннан, күңел җылысыннан төрле сәбәпләр аркасында мәхрүм ителгән балаларны яклау.

### 4. Бурычлар.

- Хатын-кызларны җәмгыять эшләре белән идарә итүгә актив җәлеп итү.
- Күп балалы гаиләләргә, ялгыз аналарга матди һәм мораль ярдәм.
- Гаиләне, аналарны ныгыту, баланың хокукларын яклау.
- Җирлек территориясендә яшәүче рус һәм башка халыкларның милли традицияләрен саклау.

5. Хатын-кызлар советы җыелышлар үткәрү мәсьәләләрен мөстәкыйль рәвештә хәл итәргә хокуклы, хатын-кызлар советының җирле шартларны исәпкә алып эшләү ысулларын билгели. Хатын-кызларның, гаиләнең, баланың хәлен яхшырту мәсьәләләре буенча җирлек администрациясенә тәкъдимнәр бирергә.

### 6. Оештыру төзелеше.

Хатын-кызлар советы утырышлары 2 айга 1 тапкыр уза.

7. Хатын-кызлар советының эшен исәпкә алу, аның рәисе һәм секретаре тарафыннан башкарыла. Исәп документларына түбәндәгеләр керә:

- Хатын-кызлар советы эше планнары.
- Хатын-кызлар советы утырышлары протоколлары.

- Хатын-кызлар советы әгъзалары исемлеге.
- Эшләнгән эш турында хисаплар.

Актаныш муниципаль районы Хатын-кызлар советы - Актаныш авыл җирлегендә яшәүче хатын-кызлардан торган ирекле җәмгыять. Хатын-кызлар башка иҗтимагый хәрәкәтләр, оешмалар белән элемтәдә торалар. Хатын-кызлар советы гаиләләргә ярдәм күрсәтә, социаль проблемаларны хәл итә, җирлекнең, районның иҗтимагый эшләрендә актив катнаша.

Хатын-кызлар советы эшчәнлегенең төп юнәлеше - имин булмаган гаиләләр белән эш алып бару, әхлакый һәм рухи агарту.

Барлык сораулар һәм тәкъдимнәр белән авыл гражданнары, сорауларның игътибарсыз калмаячагын белеп, хатын-кызлар советының теләсә кайсы әгъзасына мөрәҗәгать итә ала.

Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге каршындагы хатын-кызлар советы составы

| т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | эш урыны | Биләгән вазифасы |
|---|---|---|---|
| 1 | Вәлиева Р.К.- Хатын-кызлар советы рәисе | пенсионер | |
| 2 | Латыпова Д.С.-Хатын-кызлар советы рәисе урынбасары; | пенсионер | |
| 3 | Хафизова ЛГ- Хатын-кызлар советы секретаре | пенсионер | |
| 4 | Сәетова Ю.Ф. | пенсионер | |
| 5 | Нурлыева АЗ. | пенсионер | |
| 6 | Закирова З.Х. | пенсионер | |
| 7 | Шаймарданова А.М. | Актаныш СИК | техработник |

2018 елга Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге каршындагы Хатын-кызлар советының эш планы

| 1.0ештыру чаралары | | | |
|---|---|---|---|
| т/б | Чараның атамасы | Срогы | Җаваплы башкаручы |
| 1 | Актаныш авылы җәмәгатьчелек советы белән берлектә балигъ булмаганнар арасында караучысызлык һәм хокук бозуларны профилактикалау көннәрен үткәрүдә катнашырга | ай саен | |
| 2 | Актаныш муниципаль районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләре белән берлектә эшсез хатын-кызларны эшкә урнаштыру мөмкинлеге турындагы сорауларны индивидуаль тәртиптә карарга | ай саен | |
| 3 | яшьләр һәм башка затларның хокук бозуларын булдырмау максатыннан (чаралар үткәрү планы буенча)җирлекнең массакүләм чараларында дежурлыкта катнашырга | ай саен | хатын-кызлар советы графигы буенча |
| 4 | нәтиҗәләр буенча хатын-кызлар советы эшчәнлеген анализлау, аны камилләштерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр эшләү | ай саен | хатын-кызлар советы әгъзалары |
| 5 | җәмгыятьнең аерым игътибарына мохтаҗ булган хатын-кызларны, күп балалы, ялгыз аналарны, олы яшьтәге ялгызларны һ. б. исәпкә алу) | ел дәвамында | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 | Торак пунктта яшәүчеләрнең гаилә булдыру тәҗрибәсен гомумиләштерү (соңыннан мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында,Актаныш җирлеге сайтында бастырып чыгару) | ел дәвамында | |

Гомуми профилактик чаралар

| № т/б | Чараның атамасы | срогы | җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | социаль иминлексезлекнең сәбәбен ачыклау максатыннан, участок полиция вәкаләтлесе, торак пунктның җәмәгатьчелек советы белән яшәү урыны буенча бару:<br><br>алкоголь кулланган гаиләләр; балигъ булмаган хокук бозучылар | ай саен | |
| 2 | Медиклар, җәмәгатьчелек советы, мәгариф учреждениеләре коллективлары белән берлектә, имин булмауның башлангыч стадиясендә булган гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны ачыкларга. Гражданнар белән индивидуаль-профилактик эш алып барырга | ел дәвамында | |
| 3 | Җирлекнең полиция һәм җәмәгатьчелек советы белән хезмәттәшлек итү, алкоголь белән законсыз сәүдә итү урыннарын, ялган алкоголь продукциясен ачыклау буенча рейдлар үткәрү | ел дәвамында | хатын-кызлар советы |
| 4 | | ел дәвамында | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Авыл җирлеге җәмәгатьчелек советы белән берлектә эчкечелек, наркомания һәм тәмәке тарту һәм башка хокук бозуларны кисәтү максатыннан яшьләрнең күпләп булган урыннарына рейдлар үткәрү | | хатын-кызлар советы |
| 5 | төзекләндерү мәсьәләләре буенча яшәү урыны буенча әңгәмәләр оештыру | ел дәвамында | үзләренең урамы буенча хатын-кызлар советы әгъзалары |
| Хатын-кызлар советы утырышлары | | | |

| № т/б | Чараның атамасы | Срогы | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Җирлек хатын-кызлар советының 2018 елга бурычлары турында - эш планын раслау» түгәрәк өстәле | Май 2018 | |
| | Халыкара балалар көнен үткәрүдә катнашу (1 июнь) | | |
| | җирлекнең социаль паспортын төзүдә катнашу | | |
| 2 | Халыкара гаилә көнен үткәрүдә катнашу (8 июль) | Июль 2018 | |
| | "Безнең тату гаилә" фотоконкурсын оештыру | | |
| 3 | имин булмаган, аз тәэмин ителгән гаиләләрдәге балаларны тәрбияләү эше | июль 2018 | |
| | Күпбалалы гаиләдә балаларны тәрбияләү буенча тәҗрибә уртаклашу | | |
| 4 | Хатын-кызлар бәйрәмен үткәрүдә катнашу | 2018 февраль | хатын-кызлар советы |
| 5 | Җиңү бәйрәмен уздыруда катнашу | 2018 апрель | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 | Сәламәт яшәү рәвешен, гаиләдә һәм балалар бакчасында социаль иминлекне тәэмин итү буенча мәгариф учреждениеләре (балалар бакчалары) эше турында | Октябрь 2018 | |
| 7 | Авыл яшьләре арасында спортны үстерү, алкоголизмга наркоманиягә каршы көрәш буенча профилактик эш, авыл яшьләре арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау турында | Август 2018 | |
| | картлар һәм ялгызлар, (җирлек учреждениеләре коллективлары белән берлектә). | | |
| 9 | Каникул вакытында балаларның, яшүсмерләрнең җәйге ялын оештыру | июнь-август 2018 ел | |
| 10 | «Авылның иң яхшы ишегалды» конкурсын оештыру һәм үткәрү турында | Сентябрь 2018 | |
| 11 | Өлкәннәр көнен көнен үткәрүдә катнашу турында<br>социаль яклanган, өлкән гражданнар белән эшләү | Октябрь 2018 | |
| 12 | Әниләр көнен үткәрүдә катнашу турында | Ноябрь 2018 | |
| 13 | Инвалидлар көнен үткәрүдә катнашу | 2018 елгы декабрь | |
| 14 | авыл җирлеге хатын-кызлар советы эшенә нәтиҗәләр ясау | декабрь 2018 ел, гыйнвар 2019 ел | |

Актаныш муниципаль районы
Актаныш авыл җирлеге каршындагы
хатын-кызлар советы рәисе Р.К.Вәлиева